КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2022 ел, 12 сентябрь    г.Казань    № 981

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 ноябрь, 842 нче; 2017 ел, 15 август, 577 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2018 ел, 9 июль, 559 нчы; 2018 ел, 15 декабрь, 1145 нче; 2020 ел, 9 июль, 569 нчы; 2021 ел, 13 август, 709 нчы; 2022 ел, 15 март, 235 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең 2 бүлекчәсендә:

2.5.1 нче таблицаның «Су саклау зонасы» юлындагы 2 графасында:

икенче абзацта «туфракларның уңдырышлылыгын җайга салу» сүзләрен «туфрак уңдырышлылыгын арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«зиратлар, үләт базларын, җитештерү һәм куллану калдыкларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулый торган һәм агулы матдәләрне урнаштыру объектларын, радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру, шулай ук балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектларында рөхсәт ителгән иң чик концентрацияләре билгеләнмәгән пычраткыч матдәләр белән территорияләрне пычрату;»;

2.14.1 нче таблицаның «Гидрологик һәм гидрогеологик процесслар таралу зоналары» юлындагы 2 графасында:

өченче абзацта «туфракларның уңдырышлылыгын җайга салу» сүзләрен «туфрак уңдырышлылыгын арттыру» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «җитештерү һәм куллану калдыкларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулый торган һәм агулы матдәләрне күмү урыннарын» сүзләрен «җитештерү һәм куллану калдыкларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулый торган һәм агулы матдәләрне урнаштыру объектларын» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин